ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**Постановление** **Карар**

№ 312 от «01» 09 2026 г.

Мамадыш муниципаль районы Башкарма
комитетының 2022 елның 12 августындагы
«Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү
программасын (балалар бакчалары) гамәлгә
ашыручы мәгариф учреждениеләрендә
балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентын
яңа редакциядә раслау турында» 138 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2026 елның 30 июлендәге 9937/26 һәм 31 июлендәге 9973/26 номерлы хатлары, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2026 елның 20 июлендәге «Укытучыларга ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 498 номерлы Указы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 августындагы 138 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын (балалар бакчалары) гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (алга таба –Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Регламентның 2.2. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Муниципаль хезмәт вәкаләтле орган - Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан күрсәтелә.

Юридик адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Совет урамы, 2а йорт.

Урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Ленин урамы, 107 йорт.

Эш графигы: дүшәмбе — җомга, 08:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр, төшке аш — 12:00 - 13:00.

0000013453

Белешмә өчен телефоннар: кабул итү бүлмәсе — 8 (85563) 4-01-00; ответственный за АИС «Электрон балалар бакчасы» АМС җаваплы белгече — 8 (85563) 4-01-02.

Балаларны исәпкә кую һәм мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына җибәрү максатларында гаризалар шулай ук «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең Мамадыш филиалы офисларында да кабул ителә.».

Филиалның урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, Ленин урамы 1/22 йорт.

Филиалның эш графигы: дүшәмде, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга — 08:00 - 17:00 ; сишәмбе — 09:00 - 20:00; шимбә — 08:00 - 12:00».

1.2. Регламентның 2.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә исемлекләре әлеге административ регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән оешмалар катнаша».
«Муниципаль хезмәт күрсәтүдә исемлекләре әлеге административ регламентның 10 нчы кушымтасында китерелгән оешмалар катнаша.»

1.3. Регламентның 2.7 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе Президентының 2026 елның 20 июлендәге 498 номерлы «Укытучыларга өстәмә ярдәм чаралары турында»гы Указы нигезендә, педагогик хезмәткәрләрнең балаларын мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына беренче чиратта кабул итү каралган».

1.4. Регламентның 2.8.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.8.1. Муниципаль хезмәтне кәгазьдә күрсәтү турындагы гариза әлеге административ регламентның 8 нче кушымтасында китерелгән форма буенча рәсмиләштерелә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://mamadysh.tatarstan.ru Мамадыш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.М. Ефимов